СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

## Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

**16 июль 2024 ел** **№ 134**

### Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәк булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункт нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә гамәлдәге җирлек территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмау, расланган комплекслы социаль-икътисади үсеш программасы булмау һәм Татарстан Республикасы һәм Арча муниципаль районы территориаль планлаштыру схемалары белән федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмауга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2024 елның «30» декабренә кадәр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең генераль планын эшләү кирәк булмавын танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның «01» январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов